

# 1938-2017

## Равил ага Сәйфетдинов

**Ялган шөһрәт, даннар белән түгел,**

**Эшең белән калдыр эзеңне.**

**Эзләп тапсын кеше мәхәббәте**

**Тормыш эчләреннән үзеңне.**

**«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советлар Союзы Герое В.Х. Хаҗиев исемендәге 7 нче мәктәп» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе**

## Укытучы: Хәмидова Зөлфирә Зәки кызы

## Шагыйрь, педагог, якташыбыз Равил Сәйфетдиновның якты истәлегенә. Аның тормыш юлы һәм иҗатын өйрәнү буенча сыйныф тыш чара сценарие.

Яшел Үзән кешеләре үзенең күренекле зур шәхесләре Каюм Насыйри, Афзал Шамов,Идрис Туктар, Азат Вергазов,Фаил Шәфигуллин һәм башка күп зыялы кешеләре белән горурлана ала. Мулла Иле авылында туып үскән шагыйрь, педагог, публицист, якташыбыз Равил Сәйфетдинов та шуларның берсе. Бүгенге көндә Яшел Үзәнлеләр аның иҗатына багышланган “III Төбәкара Равил Сәйфетдинов укулары”на әзерләнәләр. Безнең мәктәптә дә аның якты истәлегенә багышлап, 6, 10 сыйныф укучылары белән сыйныфтан тыш чара үткәрелде.

Төп максат: Равил Сәйфетдиновның тормыш юлы һәм иҗатын белү.
Аның шигырьләрен өйрәнү, сөйләү.

**Равил Сәйфетдиновның тормыш юлы һәм иҗаты**

**1 Укучы**

Сәйфетдинов Равил Гарәфетдин улы 1938 нче елның 14 нче октябрендә Яшел Үзән районының Мулла Иле авылында туган. Аның яшүсмер еллары һәм гомеренең күп өлеше авылында уза.Урта мәктәпне бетергәч, 1956—1961 елларда Казан дәүләт унивеситетында укый. Ул Фәрит Йосыпов, Тәлгать Галиуллиннар белән бер төркемдә укый. Җәй айларында, алар Казахстанда чирәм җирләрдә эшләгәннәр.

1956 елны Тукай клубында ул сөекле шагыйребез Хәсән Туфан белән очрашуда катнаша..”Бу төнне мин йокысыз үткәрдем. Нинди илаһи кешебез бар икән”, дип яза Сәйфетдинов Равил. Бу вакыйга аны яңа шигъри эзләнүләргә рухландыра. 1958 елда аның “Далада туган хисләр”дигән шигырьләр циклы дөнья күрә Сүз башында Мәхмүт Хәсәнов аның иҗатына матур бәя бирә.” Җырла, Галия”, “Дала юлында”,”Казах кызы” шигырьләре далада язылган. Аны “Чирәм җирләрне үзләштергән өчен” медале белән бүләклиләр

**2 укучы**

Студент елларыннан. ” Без бер группада укыдык. Бер гаилә кебек яшәдек. Аның соңгы көннәренә кадәр хәбәрләшеп, бер- беребезнең хәлләрен белеп тордык.Талантлы, шигырьләр язды.Тормышында үзенең лаеклы урынын табып яшәде. Гомер буе хакыбызга хезмәт итте” - Фәрит Йосыпов.

Галиуллин Тәлгать Гали улы Сайланма әсәрләрендә басылган “Шигырь Мәҗнүнен”дә Равил Сәйфетдиновның иҗатына күзәтү ясап, анализлап, зур бәя бирә.“Казан дәүләт университетының йөзек кашы, алтын бөртеге кебек кадерле татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укучылар арасында Р. Сәйфетдинов һәр яктан кабатланмас шәхес иде. Шигырь җене кагылган, матурлык орлыгы салынган Равил гомеренә шигырь  Мәҗнүне булып калды” дип язды.

**3 укучы**

1961—1963 елларда Самара өлкәсендәге Гали урта мәктәбендә укытучы булып эшләгән. **Бәхет үзәне хуҗасы..**

Кулыма Равил Гарәфетдин улы СӘЙФЕТДИНОВның “Бәхет үзәне” дип аталган шигырьләр китабы килеп эләккәч, шатлык-куанычларымның иге-чиге булмады. Ул бит 1961 - 1963 елларда Казан Дәүләт университетын тәмамлаганнан соң, безнең Похвистнево районының Гали авылында укытучы булып эшләгән иде. Йомшак күңелле, барлык кешеләрне дә эчкерсез ярата белә торган һәм үзе дә халык тарафыннан бик тә үз ителүче зыялы шәхес булып истә калган ул.  Безнең мәктәптә бары ике ел гына эшләгән Равил ага балаларга бөтен көчен биреп, татар, рус, немец телләрен укыткан. Нәкъ менә шушы Гали авылында ул укучылар йөрәгенә юл табу серләренә төшенә, һәр дәрескә иҗат ялкыны белән керә, үзенең максатына ирешә, шуннан үзенә биниһая шатлык, ләззәт ала. Һәм менә хәзер “Бәхет үзәне”. Анда шагыйрь үзенең хезмәт юлын башлап җибәргән Гали авылына багышлап язылган шигыре дә урын алган. Мин аны сезгә дә тәкъдим итәргә булдым, хөрмәтле “Бердәмлек” газетасы укучылары.

**4 укучы**

Илзат шиырьне укый

“Сиңа барып төшкәч, шаклар каттым:
Коммунизм җиткән чагында
Дәһри СССРның уртасында
Урнашкан бу шәһри авыл да.
Өч мәчет бит гөрләп эшләп тора
Өч манара балкый нурланып.
Урта мәктәп тора хозурланып,
Азан моңнарына уралып.
Кайгыларым монда юылып төште,
Мондый халәт күргән юк әле.
Фатир хуҗам Коръән хафиз икән
- Җанга үтеп керә мәкаме.
Монда халык сөйли чын татарча,
Туган телем яши гөрләтеп.
Тукай телен укыту - зур мәртәбә,
Булдым монда ничек хөрмәтле.
Казаннан бик ерак-ерак җирдә
Өзелеп сөйгән газиз милләтем
Маңгаемнан сыйпап юатты да

Сабырлыкка мине өйрәтте
Мәктәбендә балалары хәтсез
Һәр сыйныфта утыз йә кырык
Шулар мине ничек яраттырды,
Газапларым китте яктырып.
Тормыш күргән кеше булып кайттым
Мин Галидән Мулла Иленә.
Хак Тәгалә сынауларын узып,
Халкым йөген салып иңемә. ..
Күрсәтәләр бүген бар
Рәсәйгә Үрнәк итеп Гали улларын.
Бар Рәсәйдән кунак чакрып алып
Гөрләтәләр сабантуйларын.
Экраннардан күренә бар Рәсәйгә
Мин яраткан Гали таулары.
Шул тауларга басып карап торам
Яшьлегемнең алтын елларын.
Кар китүгә, иң-иң биек җирдә
Ясап язның тәүге бәйрәмен,
Кырык бала белән без кададык
Үзебезнең сыйныф байрагын.
Менә ничек матур итеп тасвирлаган, югары бәя биргән шагыйрь Гали авылына. Нәкъ менә шушы дини авыл аңа тора-бара дингә ныграк тартылырга, аның асылын аңларга ярдәм иткәндер дә инде.”Гали авылы кешеләре белән эти гомеренең азагына кадәр элемтәдә яшәде” дип яза улы Рөстәм Сәйфетдинов.

**5укучы**

1963 елдан башлап Равил аганың бөтен гомере Татарстанның Яшел Үзән районындагы үзенең туган Мулла Иле авылында уза. Авыл мөгаллиме буларак, татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, алман теле, гарәп теле, дин тарихы фәннәрен укыткан. Биредәге мәктәптә ул директор урынбасары да(1968—1970 елларда), 1971—2000 елларда директор да булып эшли. Мәктәп җитәкчесе булса да, гомергә укытучы булып кала. Аңа “Россиянең мәгариф отличнигы”, “Татарстанның атказанган укытучысы” дигән югары исемнәр бирелгән. 2017 елда рухи-әхлакый традицияләрне үстерүдә, тынычлык һәм конфессияара килешүне ныгытуда зур көч куйганы өчен Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләнә. Кайларда гына булмасын, лирик геройның туган ягын сагынып яшәве үзәктә тора.Балалык, яшүсмер еллары үткән, табигате белән җанга якын җир аңа бик кадерле.

Күпме шәһәрләрне күрмәдем мин,
Күпме хәйран калып йөрмәдем.
Тик алардан Шашкын сагыну белән
Сиңа алып кайтты йөрәгем **.” Яшел Үзән “җыры**

**6 укучы**

Аның шигырьләрендә туган як һәм аның кешеләренә, халкыбызның матур сыйфатларына, традицияләренә соклану, шулар аша милләтнең бүгенгесе һәм киләчәге турында кайгырту. Шул ук вакытта “якты нур”сүзе ышаныч, өмет, алып килүче алдагы көн символы булып килә.Ул туган ягының, аның кешеләренең киләчәгенә ышаныч белән карый.

Чакрымнарга сузып урамнарын,
Иркәләнеп тигез үзәндә,
Җәйрәп ята шанлы Мулла Илем,
Рәхәт биреп безнең күзләргә.
Зур авылда алтын куллы халкым
Яши бердәм, тыгыз тупланып.
Үз теленә зур тыюлык булып,
Бер-берсеннән куәт-нур алып
Җуя күрмик сигез гасыр корган
Зур тарихны - рухи байлыкны.
Үкенүдән зар еламас өчен,
Тормышларын көйлик халыкның
Казаннардан якты нурлар алып,
Матур даның белән ил гизеп
Гасырларда яшә, Мулла Илем,
Биш йөз йортка утлар тергезеп.

**7 укучы**

2005 елдан алып Мулла Иле мәчете имам-хатыйбы вазифаларын башкара."Һәрбер дини чарага ул олы иман, зур тырышлык белән әзерләнә", - диләр аның турында авылдашлары. Шул ук вакытта шагыйрь, бүгенгенең ерак үткән белән тоташуын һәм тоташырга тиешлеген белә. Үзенең гомер юлы нәсел җебе бик еракка барып ялгануын да ачыграк белә. Нәсел җебен эзли, барлый. Нәтиҗәд, аның поэзиясенә яңа тарихи катламнар, яңа мотивлар килеп керә. Тукай турындагы язылган ”Заманыбыз мохтаҗ тукайлыкка”публицистик поэсында.”Хәсән Туфанга”,”Һади Такташка хат”,”Вәисиләр турында хикәят”ендә, дә шушы бәйләнешне күрмичә мөмкин түгел.

**8 укучы**

Якташыбыз Равил абый Сәйфетдинов туган авылының тарихын өйрәнә, ул тарихны китап итеп тә бастырып чыгаручы кеше.

“ Мулла Илендә Казан ханлыгы чорында дәрәҗәле кешеләр яшәгән, – дип сөйләде авылның аксакалы Равил абый Сәйфетдинов. – Мондый зур һәм нәфис хәрефләр чокып язылган, мәгънәви орнаментлар төшерелгән кыйммәтле ташларны, каяндыр ераклардан атлар белән алып кайтып, аерым кешеләргә генә куйганнар. Бу ташлар авылыбызның бер гектар чамасындагы агач үсми торган аланлыгында утыра. Ул аланлыкта печән чабалар, әмма анда мәет күммиләр. Күмеп караганнар иде – сөякләр чыга. Ул борынгы зират мәйданы, монысы бәхәссез. Аның зурлыгына карап, Мулла Иленең борынгы, зур авыл икәнен чамалап була. Әмма 1528–1768 еллар эчендә мондый мәһабәт ташлар куелмаган, чөнки чуалышлар

Казанны алганчы ук башлана, акрынлап рус гаскәрләре Тау ягын басып ала. Һәм Мулла Иленнән унбиш чакрым ераклыкта гына Зөя тамагында Свияжск ныгытмасы төзелә. Мулла Иле дәһшәтле яуларның үзәгендә кала. Ләкин шул чорда да иманын, нигезен югалтмый ул…»

**9 укучы**

Халык азатлыгы өчен көрәштә һәлак булган батырлар, үткән һәм хәзерге Казан турындагы шигырьләре дә шагыйрьнең тарихи фикерләү юнәлешендәге эзләнүләрен чагылдыралар. “Мәр-мәр ташны үбә таң җиле” ”Егерменче гасыр, мин синеке””Һәйкәлләре монда әтиләрнең”шигырьләрен әйтергә була.

Ватан өчен шәһит иткән алар,
Без яшәсен өчен үлгәннәр
Үзләре гел яшь көенчә калып,
Гомерләрен безгә биргәннәр

**10 укучы**

Шагыйрь ягы - басу-кырлар, чишмә, инешләр, урманнар иле. Шунлыктан аның шигырьләрендә күбрәк авыл юллары, ирләрдәй нык имәннәр, рәт-рәт булып баскан төз чыршылар күзләрне иркәләгән арыш басулары белән очрашасың. Аның әсәрләрендә туган як темасы бөтен иҗатын иңләп алган.Туган җир белән бәйләнешле туган якның табигате, матурлыгы турында язган шигырьләре эзлекле үстерелә, ул әдипкә яшәү көче, иҗат дәрте бирә.

Яратам мин сине, хезмәт белән
Дан казанган матур Мулилем.
Кырларыңда сине сөюемә
Җавап булып үсә мул иген.
Буйларыңда сихри болыннар,
Яшел таллар - нечкә билләре.
Камышларга сыенып тын гына
Күккә карап яткан күлләре.
Менә Комсу, Кухмар, Чиркәлше,
Томбый, Бучук, Бәчүр, Илмышык!
Төнбоеклар өчен бик рәхәт,
Сулар тонык, йомшак һәм ышык.
Уртасында яшел үзәннең
Җәйрәп ята гүзәл Мулилем.
Кырларыңда үсә мул иген
Мәхәббәтем яме шул минем.

Аның өчен генә туган җире кадерле, аңа җан рәхәте, күңел тынычлыгы бирә, шунда ук вакытта ул төшенчәләрне киңәйтеп кеше яшәеше, хезмәте белән тыгыз бәйләнештә күрсәтә.

Кил Күгешнең иркен кырларына,
Күр үскәнен ничек кәбестә.
Безнең якның гүзәл кешеләре
Могҗизалар ясый һәр эштә.

**11 укучы**

Равил Сәйфетдинов иҗатында мәххәббәткә багышлаган шигырьләре шактый урын алып тора. Яшәешкә җан өргән, тормышка ямь биргән сөю хисен үзенчәлекле сурәтли. Мәхәббәт утында янган лирик геройның уй-хисләре тормышчанлык белән үрелеп бара.

Күзләреңнең диңгезенә
Табынуым, пакълегем белән
Мәңгелеккә керәсем килде(“Кайт инде”)
Оркыяның карашыннан
Язгы нурлар бөркелә(“Күл буенда”
Яндырырга, көйдерергә
Сиңа мәхәббәт килде(“Беренче мәхәббәт”)
Ул кызыйга һәркем үлеп гашыйк,
Әллә ние белән сөйдерә.
...Чәчәк биреп китә-исертә,
Йөрәкләргә серле көч бирә.(“Мәңгелек кыз”)
Бетмәс куәт алдым карашыңнан,
Күзләреңнең җете карасыннан
Көчле сөю утын эчтем мин.(Юк, мин бекайчан да яр табам дип...”)

**Укучылар Сәйфетдинов Равил Гарәфетдин улы турында язган фикерләрне аерым аерым әйтеп үтәләр**

“Мөгаллим дә, шагыйрь дә булган сәләтле шәхес” Илдар Юзеев

**“Тамыр тирәнлеген яфрак тоя” Оныгы Сәйфетдинов Искәндәр**

Равил бабам шигырьләренә үз вакытында Хәсән Туфан югары бәя биргән үзенчәлекле шагыйрь. Мәктәп елларыннан алып бүгенге көнгә кадәр ул иҗат белән шөгыльләнә. Аның “Ак төнбоек күлләрдә” дигән шигырьләр циклы Илдар Юзеевның сүз башы белән басылып чыккан(1998). Халык шагыйре аны үзе педагог, үзе шагыйрь булган сирәк шәхесләрнең берсе итеп санаган. 2000нче елда бабайның “Кичке шәфәкъ” исемле шигырьләр китабы дөнья күрде. Гаҗәп игътибарлы һәм хәтерле кеше буларак, ул авылдагы һәм якын-тирәдәге хикәятләрне, мәзәк хәлләрне хәтерендә сеңдереп бара һәм аларны, әдәби яктан эшкәртеп, вакытлы матбугатта бастырып тора.

...Авыл тарихы буенча ул бик куп материаллар туплаган, шагыйрь Баһаветдин Вәисов турында поэма да язган, аның «Мулла Иле» дигән шигырен композитор Риф Гатауллин көйгә дә салган.

**Равил Сәйфетдиновка багышланган кичәдән соң фикерләр:**

- Мөхтәрәм Равиль абыйның гомере буе сузылып барган кызыл җеп инде бу шигырь. Үзе ахирәткә күчсә дә, шигырьләре белән укучылары күңелендә яши бирә.

-Равил Сәйфетдинов һәм «Яшел Үзән». Газета нәшер ителә башлаган беренче көннән үк хезмәттәшлек итте ул безнең белән. Ә хәзер без бер ятим шикелле.

- Равил абый, язылмый калган шигырьләрегез – балаларыгызда, оныкларыгызда, тәрбияләгән укучыларыгызда. Алар Сез җиткерергә теләгән фикерләрне тормышка ашырыр, Сезнең кебек, милләт өчен янып яшәр Әнә

шушы исем астында Мулла Илендә узган чара күбебезне моңсулатты, елатты.
- Исән булса, бу көннәрдә халык укытучысы (мин аны шулай атыйм), шагыйрь Равил Сәйфетдиновка 84 яшь тулган булыр иде. Бу кичә Равил абыйны хөрмәт иткән барлык кешене бергә җыйды. Яратмаслык, хөрмәт итмәслек кеше түгел иде шул – чын КЕШЕ. Әнә шуңа да зал тутырып килгәннәр.
- Равил абыйны юксынып сөйләгән һәркемнең кулында аның китаплары иде.
- Укучысы, Казан дәүләт мәдәният институты доценты Илсөяр Шиһапова әйткәнчә, аның китаплары бер сулыш белән укып чыга торган түгел, берәм-берәм укып, сеңдереп, кайта-кайта укый торган шигырьләр...
- Юксынып та, горурланып та утырдым – аның дәвамчылары күпме?! Кичәгә кайтканнары, кайта алмаганнары? Күбесе милләтебез, телебез, динебезне үстерү юлында. Улы, 16 нчы татар мәктәбе директоры Рөстәм Сәйфетдинов – этисе юлын, этисе эшен дәвам итәрлек шәхес буларак өлгереп җитте.
- Равил Сәйфетдинов һәм «Яшел Үзән». Хәтерләсәгез, «Фирүзә» дә бик сирәк дөнья күрә. Равил абыйсыз ... Юк, яхшы шигырь язучылар юклыктан түгел. Ничектер, алтын баганасын югалтты шикелле ул.

**Укытучы, шагыйрь Равил Сәйфетдинов иҗатына багышланган III Төбәкара Равил Сәйфетдинов укуларына катнашучылар һәм түгәрәккә йөрүчеләр арасында шигырьләр сөйләү.**

1. Зинатуллин Алмаз Рамилевич 6класс“Яңа елны каршылау”
2. Латыпов Самат Айратович “Татарстан”
3. Сабиров Ризат 1класс“Егет булсаң”
4. Бариева Зарина”Яшел Үзән гимны”
5. Сафиуллина Алсу “Бәхетле син,кешем”
6.Шәфигуллин Тамерлан “Барлык килештә төрләнә Казан”
7.Фәйзуллин Амир Разилевич “Гел яшь калсын, яшел торсынМилли Үзән”

**Укучылар, сез Равил Сәйфетдинов шигырьләрен ятлагансыз, матур итеп, сәнгатьле сөйләдегез. Бүген Сабиров Ризатның чыгыгышы сезгә ошады. Аның дәү әтисе, дәү әнисе Мулла Иленнән , алай гына түгел, Равил бабасы аңа исем дә бирүче**
**9 декабрь көнне шулай матур итеп чыгыш ясарсыз дип ышанам.**